ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05 06 2024 г. № 587

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукларын гамәлгә ашырганда сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча 2023 елның 20 сентябрендәге 35 номерлы мәсьәләләрне хәл итү буенча һәм Түбән Кама муниципаль районы Советының 2023 елның 20 сентябрендәге 50 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турындагы килешүне исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы һәм Түбән Кама шәһәре милкендәге күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел түләүне кичектереп тору срогы дип билгеләргә.

2. Арендалана торган мөлкәткә түләү тәртибен (бер үк вакытта яисә өлешләп түләү), шулай ук әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срокларын сайлау хокукы арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Вакытыннан алда түләү бирелә торган акчалар суммасына процентлар Россия Федерациясе Үзәк банкының арендага бирелә торган милекне сату турында игълан бастырып чыгару датасына гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өчтән бер өлешенә тигез булган ставкадан чыгып исәпләнә.

4. Арендалана торган мөлкәтне өлешләп түләү сатып алучының карары нигезендә вакытыннан алда башкарылырга мөмкин.

5. Арендага бирелә торган мөлкәтне арендатор кичектереп сатып алган очракта, күрсәтелгән мөлкәт сатучының залогында тулысынча түләнгәнче була.

6. Арендалана торган мөлкәтне аерылгысыз яхшыртуның бәясе, әгәр күрсәтелгән яхшыртулар арендага бирүчеләрнең ризалыгы белән башкарылган булса, сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләү хисабына исәпләнә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы М.Р. Шаһиволиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов